**Еллар үткән саен ветераннар,**

**Сирәгәя инде сафларыгыз,**

**Сезнең хакта хатирәләр туплап,**

**Истәлекләр җыяр чакларыбыз....**

**Язмышыгыз ай-һай авыр булган,**

**Ачлы туклы узган балачак....**

**Сынауларны җиңә алуыгыз,**

**Горур булып алга баруыгыз**

**Яшьләр өчен үрнәк булачак!**

# Фәләхова (Гаянова)
# Сафия Фәйзелгаян кызы



Мин Җөринең указлы мулласы, Әхмәтшакир улы Фәйзелгаян кызы Сафия (Гаянова), 1926 елның 1нче февралендә Саба районы Алан-Җөри авылында туганмын. Сатыш тулы булмаган урта мәктәбенең 7нче классын тәмамлаган елны Ватан сугышы башланды. Сугыш елларында колхозда эшләргә туры килде. “Арыслан” колхозы гомуми җыелышы мине, 15 яшьлек кызны - бригадир, райком тәкъдиме белән Сатыш кызы Гөлбикәне колхоз рәисе итеп сайлады. Без ике яшь кыз әйбәт кенә эшлибез, үзебезчә тырышабыз инде. Куелган хезмәт бушка китмәде. Бу елны иген уңышы әйбәт булды. Ирләр сугышка китеп тора.Картлар, хатын-кызлар һәм яшүсмерләр көче белән уңыш югалтуларсыз җыеп алынды. Дәүләт җиткергән ашлык сату планы үтәлде. Орлыкка җитәрлек салынды. Колхозчыларга хезмәт көннәренә дә бирелде.

Озакка сузылган авыр сугыш елларында эшләмәгән эш калмады: хисапчы да, завхоз булып та эшләдем. Беләккә көч-куәт кергәч, авыр хезмәтләр башланды: җәй көне иген эшендә, кышын урман кисүдә. 1945 елның апрель аенда мине Киров өлкәсенә торф чыгару эшенә җибәрделәр. Тынычлык язын шунда каршыларга насыйп булды. Авылга кайтуга, тагын колхоз эшендә җиң сызганып эшли башладым. Эшкә барышлый, районнан вәкил килгән, сине чакыралар дип, иптәш кыз туктатты. Алъяпкыч күкрәгендә медаль ялтырый, минем дә алъяпкыч күкрәгенә “1941-1945 нче Бөек Ватан сугышы елларында фидакярь хезмәт өчен” ( “За доблестный труд”) медален беркетте. Сугыш туктады, инде укуны да дәвам итәргә вакыттыр, соң булса да, уң булсын дип, тәвәккәлләп, Саба урта мәктәбенең 8 нче сыйныфына килдем. Аны тәмамлагач, Казан педагогия училищесының II курсына кабул иттеләр. Мин аны читтән торып укып, уңышлы тәмамлап, “Башлангыч мәктәп укытучысы” дигән диплом

алдым. Хезмәт юлымны 1947 елда Оет башлангыч мәктәбендә башладым. 1948 елда Юлбат мәктәбенә күчерделәр. Анда лаеклы ялга чыкканчы, балаларга башлангыч белем бирдем. Педагогик  хезмәтем 34 елга сузылды. Намуслы хезмәтемне хөкүмәтебез югары бәяләде, “Хезмәт ветераны ” исеме һәм юбилей медальләре белән бүләкләндем.

Вәгыйзь исемле фронтовик егеткә кияүгә чыктым. Ирем белән 6 бала: 4 ул, 2 кыз тәрбияләп үстердек. Бүгенге көндә 11 оныгым һәм 3 оныкчыгым бар. Кызганыч, улларымның 2се вафат инде. Олы улым игезәк сыңары  Рафаэль Казан Химиклар сараенда киномеханик һәм техник җитәкче вазифаларын намус белән 20 елдан артык үтәде. Исеме, рәсеме химиклар сарае каршында Почет тактасында торды. 1953 нче елда туган улым Камил  Фәләхов, Химия технология институтын (КХТИ) тәмамлап, соңгы сулышына  кадәр Менделеев химия заводында инженер булып хезмәт куйды.

Ике улым үз авылыбызда. Игезәк сыңары Наил улым, лаеклы ялга чыкканчы,  колхозда механизатор һәм тимерче эшендә эшләде. Күршедә үз гаиләсе белән яши. Кызларым да тормышта үз урыннарында таптылар: намус белән эшләп, балалар үстереп, лаеклы ялга чыктылар. Кече улым Замир Юлбат урта мәктәбендә физкультура дәресләре укыта. Киленем татар теле һәм географиядән  укучыларга белем бирә. Оныкларым Фәннур төзелеш һәм архитектура буенча  югары белем алып (КГАСУ), армиядә хезмәт итеп кайтты.



Хәзер Саба аграр көллиятендә эшли. Фәридә кызыбыз Казан федераль университетының экономика факультетының икенче курсында белем ала.

Улым Замир һәм киленем Фирдания тәрбиясендә бик әйбәт гомер кичерәм. Рәхмәт аларга, тигез яшәп балаларының һәм булачак онdone онкларының игелеген күреп, саулык белән тигез яшәсеннәр иде, дип хәер догада торам.

Бөек Җиңүнең 30, 40, 50, 55, 6065, 70 еллык юбилей медальләре, 1946 елда “1941-45 еллардагы батыр хезмәте өчен” медале белән бүләкләндем.



# Галиева (Шәйдуллина) Вазифа Шәйдулла кызы

Саба районының Тенеки авылында яшәүче Вазыйфа әби Галиева (Шәйдуллина Вазыйфа Шәйдулла кызы) 1914 нче елның 23 гыйнварында Юлбат авылында эшче гаиләсендә туган. Белеме: 4 класс. Гаиләләре ишле булган: үзләре дүрт бала (Зиннәтулла-сугышка Донбасстан китә, Сөнгатулла-сугышка Грузиядән китә һәм шунда кайтып вафат була, Мәлиха, Вазыйфа), тагын – тугыз үги апа, абыйсы. Бүген бертуганнарыннан үзе генә исән-сау. Ишле гаиләнең көнкүреше заманасына күрә җитеш булган, хуҗалык тулы мал-туар тотканнар, иген иккәннәр. Ләкин 1920 елда ярты авыллары яна, халык йортсыз-икмәксез кала. 1921 нче елгы ачлыкны бик авыр кичерә алар. Күмәк хуҗалыклар оеша башлагач, Вазыйфа әбиләрнең дә малларын алып чыгып китәләр. Ачлык-ялангачлык чорнап алган елларның челләсендә Вазыйфа әби тиңдәшләре белән урак урган, кышның зәмһәрир салкынында урман кискән. Зифа кызлар ничек сынмаган да, сыгылмаган. Аның өстәвенә ашау да такы-токы гына булган. Авыл кешесенең абзар тутырып мал-туар асрап та, туйганчы ит ашаганы булдымы икән әле ул заманда?! Озак яшәүне күздә тотмаган ул чор кешеләре, кычыткан ашый-ашый ачтан үлмәс өчен тырмашканнар. Алар матур яшьлекләренең үткәнен сизмичә дә калганнар икән.

Үсмер кыз булып өлгергәч, “вербовка” белән читкә эшкә чыгып китә Вазыйфа әби. Ипи дә граммлап кына бирелә торган елларда Казанда фабрикада бияләйләр тегә, аннан соң Арчада кирпеч заводында эшли. Егерме биш метр тирәнлектәге Кизель шахталарына да төшеп эшләргә туры килә аңа. Туган йортына кайтып, өч көн торганнан соң, сугыш башлануы турында ишетә. Авылдашларын сугышка озата. Үзенә дә алар артыннан китәргә туры килә. Барнаулга кадәр барып җитәләр, урман кисәләр. Вазифа әбинең бигрәк тә сугыш елларында бөтен яшь кызларны Апас районына окоп казырга җибәрүләре, гыйнвар суыгында гаскәрләр өчен 12 чакрымга сузылган 5 метр

тирәнлектәге чокыр казулары хәтерендә нык уелып калган.

Сугыштан бер аяксыз кайткан Тенеки авылы егете Галимҗан белән 1943 нче елның 9 нчы июлендә гаилә корып яши башлыйлар алар. Йорт хуҗасы тирә-якта данлыклы балта остасы, мич чыгаручы. Бергәләп көмештән төрле бизәнү әйберләре эшлиләр. Вазыйфа әби аларны Казахстан якларына кадәр алып барып сата. Булдыклылыклары белән тормышларын бөтәйтәләр, йорт-җирне яхшырталар.

Сугыш тәмамланып, тынычлык  урнаша башлагач,  Питрәчкә барып, мал табибы белгечлегенә укып кайта Вазыйфа әби. Ул чакта маллар да күпләп үлгән. Сарыклар үлеп, атлар корчаңгылап җәфалаган. Вазыйфа әби, күп авырлыклар күреп яши-яши, сабырлыгы, тырышлыгы белән кыенлыкларны да җиңәргә өйрәнә. Озак еллар мал табибы булып эшли.

Аларның 3 балалары – кызлары Таифә белән Мәфтуха һәм улы Муллаяннан туган ул-кызларның, онык, оныкчыкларның исәбенә чыгу өчен дә кул бармаклары гына җитми икән.

Вазыйфа әби бүген “Ветераннарны тораклы итү” программасы буенча салынган яңа йортында  килене Гөлфия апа белән гомер итә. Гөлфия апа - ачык йөзле, бик уңган, авылыбызның хөрмәтле кешесе. Әдәпле, әхлаклы, күркәм холыклы балалар тәрбияләп үстергән ана ул. Әбекәй киленен дә, оныкларын да хәер-догасыннан, киңәшләреннән калдырмый. Хезмәт белән тир түгеп алып барылган үткәндәге тормышы өчен күңеле тыныч аның бүген.



“Мине бик хөрмәтлиләр, аллага шөкер, балалар тыңлыйлар, хөрмәт итәләр. Ишекне ачуга: - “Әби без киттек, әби без кайттык”, -дип һәрвакыт әйтеп йөриләр. Тәмле ризыклар гына ашаталар,” - ди Вазыйфа әби. Әбинең бүлмәсе җылы, якты. Чиста, йомшак урын җирдә ятып, радио тыңлый, дөньядагы бөтен яңалыктан хәбәрдар ул. Һәрнәрсәгә дә аның үз фикере бар. Бик олы яшьтә булуына да карамастан, ачык фикерле, күркәм сыйфатлы, мөлаем ак әбинең шундый авыр тормыш юлын матур итеп, башкалар горурланырлык итеп  уза алуына сокланмый мөмкинме соң!

Тыл  ветераны. Бөек Җиңүнең 30, 40, 50, 55, 60, 65, 70 еллык юбилей медальләре, 1995 елда “1941-45 еллардагы батыр хезмәте өчен” медале белән бүләкләнгән.

# Саттарова (Җәлилова) Рафика Җәлил кызы




Минем дәү әбием - Җәлилова Рафика Җәлил кызы - 1931 елның 15 июнендә, Йосыф-Алан авылында көмешче гаиләсендә дөньяга килә. Әтисе Җәлил, әнисе Кафия исемле була дәү әбинең. Өч балалары була аларның. Ике малай арасында тугангамы, дәү әбием дә ир-егетләр кебек таза гәүдәле, эре сөякле булып үсә. Белемгә омтылышы көчле булса да,
4 класс кына бетерергә туры килә аңа.

Заманы авыр булганга, бик яшьли нужа йөген тартырга туры килә дәү әбиемә. Шул чор балаларына туры килгән авырлыкны, ач-ялангачлыкның барысын да үз башыннан уздыра дәү әбием. “Без яшь вакытта күргән авырлыкны, ачлыкны, сугыш михнәтләрен бүтән бер кешегә дә күрергә язмасын иде җир йөзендә,”- ди дәү әбием, узган гомерен күзаллап. “Без бала вакытта ашаган үлән-үсемлекләрне санап күрсәтсәм, сез ышанмыйсыз да инде хәзер аңа,”-ди дәү әбием. Ачлыктан, үлемнән алып калган үләннәрне дәү әбием бик күпләп санады. Без белмәгән балтырган, кәҗә сакалы, какы, әнис, шома көпшә, кыр суганы – болар бар да дәү әбиемнәр буыны ашап, исән-сау үлемнән алып калган үсемлекләр икән.

Балалык, үсмер, кыз чакларын бик еш искә алырга ятратмый дәү әбием. Ә менә сораган вакытта ниндидер бер җитдилек, тәвәкәллек белән сөйли ул яшь вакытларын. Яшь булганнар, матур булганнар бит яшь вакытта дәү әбиләрем. Нинди генә эш башкармаганнар алар: колхозның барлык эшләрендә катнашканнар, урман кисәннәр, вагон төягәннәр, көтү көткәннәр, бозаулар караганнар...

1941 нче елгы сугышка дәү әбиемнең әтисен яше олыгайган булганлыктан алмыйлар. Ә менә дәү әбиемнең абыйсы Габделәхәтне армиядә хезмәт иткән җиреннән сугышка кертәләр һәм ул шул сугышта үлеп кала. “Бик башлы иде Габделәхәт абыем, бик зиһенле иде, гел бишкә генә укыды бәгырем,

тик гомере генә кыска булды бичаракайның,”- дип, күз яшьләрен сөртеп ала һәрчак дәү әбием, сугыш чорын сөйли башласа. “Элек бик матур итеп, урам әйләнеп, саубуллашып чыгып китәләр иде таң белән,”- ди дәү әбием, үзләренең яшь вакытларын искә алып. Йөзләре кызарып, матурланып, алсуланып китә дәү әбиемнең андый чакларда.

Габделәхәт абыйсы бик матур җырлый, шигырьләр яза, гармунда уйный торган була аның.

Җиткән кыз булып җитешкәч, дәү әбием Йосыф-Алан егете Фоатка (дәү бабаем) кияүгә чыга. Бик матур гомер кичерәләр алар, бер малай, ике кыз үстерәләр. “Бигрәк яхшы кеше иде, бигрәк тормышчан иде, балаларны бик яратты, кулыннан барлык эшләр дә килә иде мәрхүмкәйнең, тик бераз иртәрәк гүр иясе булды бичаракай,”-дип авыр сулап куя ул тормыш иптәше – дәү бабам турында сөйләгәндә.




Дәү әбием гомере буе, бер көн дә калмыйча, колхоз эшендә булган. Иң авыр, җаваплы эшләрдә эшләгән ул. Сарыклар, бозаулар караган. 40 елдан артык сыерлар савып, пенсиягә чыккан ул. Эшләгән вакытта бирелгән грамоталар, мактау кәгазьләренең исәбе-хисабы юк. Күкрәк медальләре генә дә 15тән артык.

Менә ичмасам, яшәгән минем дәү әбием, дип горурланып куям мин әлеге медальләрне, мактау кәгазьләрен карап утырганда. 85 яшьлек дәү әбиемә исәнлек-саулык, сәламәтлек теләп калам мин.

Тыл ветераны. Бөек Җиңүнең 30, 40, 50, 55, 60, 65, 70 еллык юбилей , 1993 елда “1941-45 еллардагы батыр хезмәте өчен” медальләре белән бүләкләнә.

Оныкчыгы Дәүләтшин Рөстәм



# Сәгыйтова Рәшидә Сәгыйть кызы

1931 нче елның 2 нче июлендә Саба районының Тимершык авылында урта хәлле крестьян гаиләсендә туган (Сәгыйтова Рәшидә Сәгыйтовна, язылышкач та кыз фамилиясендә калган).

Тимершык тулы булмаган урта мәктәбендә 7 нче сыйныфны тәмамлагач, 1947-1950 нче елларда Саба урта мәктәбендә укый, аны уңышлы тәмамлый.

Сугыш башланган вакытта Рәшидә II сыйныфны тәмамлаган 10 яшьлек кыз була. Бу хәбәрне олылардан ишетә. Әтиләре Сәгыйдулла абзый, олы яшьтә булу сәбәпле, сугышка алынмый. Әсхәдулла һәм Хәмидулла исемле ике абыйсы сугышка китә. Ирләр сугышка киткәч, авылдагы бөтен авыр эш хатын – кызлар, картлар, яшүсмерләр, балалар кулына кала. Әнисе Гөлсабирага, апалары Бибисара белән Зөлхәбирәгә ияреп, Рәшидә колхоз эшенә йөри. Кечкенә сеңлесе Раузага 6 яшь була. Җәйләрен басуга чүп утарга чыгалар. Ашлык ургач, коелган башакларны җыялар. Кич белән һәр бала, амбарда үлчәтеп, көне буе җыйган бөртеген тапшыра.

12 яшь тулгач, әниләре белән урак урырга йөри башлый. Сугыш чорында авыллар буйлап сложный молотилка йөри. Ул авылда, гадәттә, атна – ун көн тора. Шул вакыт эчендә кул белән урган икмәкне суктырып калырга кирәк була. Шуңа күрә бу чорда тәүлек буе эш тукталмый. Үсмер кызлар молотилкадан салам чыгарып торалар.

Кышларын, кич утырып, йон язалар, җеп эрләп, фронтка җибәрергә бияләй, оекбаш, перчаткалар бәйлиләр. Рәшидә күп апаларга фронтка хат язарга булыша. Сугыш вакытында ашау-эчү бик кысыла. Әтиләре атлы эштә була, ул ерак араларга да йөри. Әниләре белән ике апасы гел колхоз эшендә булалар. Шулай да сыер асрыйлар, бәрәңге утырталар. Икмәк күрмәсәләр дә, гаилә

ачлыктан интекми. Җәйләрен күрше кызлары белән турыга гына, яланаяклап, Саба урманына җиләккә йөриләр. Кача – поса каен, кура җиләге җыялар. Урман каравылчысына юлыксаң, савыты–ние белән җиләгеңне алып калырга да күп сорамый. Таш бөреләрен, яфраклары белән җыеп, киптереп, чәй итеп эчәләр. Әниләре кишер, чөгендер чәе дә хәстәрли.

Никадәр авыр еллар булса да, мәктәптә укулар дәвам итә.

Сәгыйтовларның ике уллары да, авыр яраланып, контузияләр алып, озак вакытлар госпитальләрдә дәваланып, сугыш бетәр алдыннан кайтып төшәләр. Батырлыклары өчен күп медальләр белән бүләкләнгән булалар. Кече командир Хәлиулланың күкрәгендә исә ике сугышчан Кызыл Байрак ордены балкый.

1945 елның 9 май көне җитә. Өйдән-өйгә шатлыклы хәбәр ишетелә: сугыш беткән. Бар кеше урамга чыга. Кемнәрдер көлә, шатлана, кемнәрдер елый...

Сугыш беткәч тә, тормышлар авыр була әле. Исән кайткан фронтовиклар күп авыр эшләрне үз өсләренә алалар. 1947 елда Рәшидә Тимершык мәктәбендә 7 нче сыйныфны тәмамлый. Аның алга таба да укуын дәвам итәсе килә. Әтиләре, алдынгы карашлы кеше буларак, кызының бу фикерен хуплый. Шул ук елны ул Саба урта мәктәбенең 8 нче сыйныфына укырга китә. Ул елларда урта мәктәпнең олы классларында уку түләүле була. Бу исә сугыштан соңгы авыр елларда бик күп яшьләрнең уку теләген сүндерә.

1950 елда Рәшидә Саба урта мәктәбен уңышлы тәмамлый. 1954 елдан Тенеки башлангыч мәктәбенә эшкә килә. Анда 30 елга якын эшли.

Юлбат авыл егете Халиков Мөхәммәтхан белән тормыш корып, 5 бала тәрбияләп үстерәләр. 1977 елда аны Юлбат башлангыч мәктәбенә мөдир һәм рус теле укытучысы итеп күчерәләр. Лаеклы ялга чыкканчы (1983 елга кадәр), Рәшидә Сәгыйть кызы шушы мәктәптә эшли.

Бүгенге көндә Рәшидә апа Юлбат авылында улы Илнар гаиләсе тәрбиясендә яши.

Ул – хезмәт һәм тыл ветераны. Ана даны медале, Бөек Җиңүнең 30, 40, 50, 55, 60, 65, 70 еллык юбилей медальләре, 1995 елда “1941-45 еллардагы батыр хезмәте өчен” медале белән бүләкләнгән.



# Хаҗиева (Нәгыймуллина) Әлфинур Нәгыймулла кызы

Әбием Хаҗиева Әлфинур Нәгыймулла кызы 1926 елның 6 гыйнварында Юлбат авылында дөньяга килә. Сугыш башланганда аңа нибары 15 яшь була. Әтисе Нәгыйм Сафиулла улы сугышның беренче көненнән үк фронтка китә. 1942 елның июлендә абыйсы Мәүлетҗан да сугышка алына. Бөтен авырлык әбиемә һәм аның энесе Хәкимгә кала. 1942 елның көзендә әбиемне ФЗӨ гә җибәрәләр. Монда да аны авыр сынаулар көтә. 6-7 айдан, ФЗӨ таралгач, авылга кайта. Озак тормый, Юдинога баржа бушатырга китә. Баржа бушату, урман кисү кебек авыр эшләрне башкара яшь кыз. 15 - 16 яшьтә Шәмәрдәндә дә шундый ук авыр хезмәт көтә.

1944 елның ноябрендә әбием һәм аның иптәш кызы Галләмова Зәйнәп урман кисәргә китәләр. Ләкин Зәйнәп апа авырып китә һәм аны Кукмара хастаханәсенә җибәрәләр. Икенче көнне, иптәш булмау сәбәпле, әбием урманга бармыйча кала, шунлыктан аны кулга алалар. Землянкада күргәзмә суд ясала, хөкем итәләр. Төрмәдә аны яңадан-яңа сынаулар көтә: 5 - 10 кубометр урман кисү, кышларын сал саллау. 5 ай гомере шулай уза. 1945 елның маенда әбием туган йортына кайта. Әбием кайтып, 3 көн узуга, шатлыклы, күптән көтелгән хәбәр килә: сугыш беткән.

Сугыш беткәнгә быел 71 ел була. Ләкин сугыш һәм тыл ветераннарыбыз бу дәһшәтле сугыш елларының һәр көнен, һәр сәгатен бүгенгедәй хәтерлиләр. Әбиемнең күңелендә сугыш хатирәләре әле дә саклана. Безнең арабызда әби булганга сөенеп бетә алмыйм. Ул һәр ризыкның, һәр тыныч көннең кадерен белегез, дип әйтә. Без, егерме беренче гасыр балалары, шушы иркен, тыныч тормышта яшәвебез өчен бары тик кадерле, хөрмәтле ветераннарыбызга бурычлы. Бүгенге көндә ветераныбыз улы Айрат гаиләсе белән яши.

Тыл ветераны. Бөек Җиңүнең 30, 40, 50, 55, 60, 65, 70 еллык юбилей, 1993 елда “1941-45 еллардагы батыр хезмәте өчен” медальләре белән бүләкләнгән.

Оныгы Хаҗиева Гүзәл



## Муллиева
## Сания Мулли кызы

1931 елның 21 январенда  Тенеки авылында крестьян гаиләсендә туган. Тенеки башлангыч мәктәбен тәмамлаган. Белеме 3 класс.

Тегермән буасы эшләгәннәр, иген, борчак урганнар, урман кисүгә йөргән. Иштуганда вагон төягәннәр. Плугар булып эшләгән, чәчү чәчкәннәр. Сугыш беткән дигән хәбәрне авыл кешеләреннән ишеткән. Әнисе белән икесе генә яшәгәннәр. Лаеклы ялга чыкканчы “Искра “ колхозында төрле эшләрә эшләгән. Хәзерге вакытта Ханипов Альберт гаиләсендә, Тенеки авылында яши.

Тыл  ветераны. Бөек Җиңүнең 30, 40, 50, 55, 60, 65, 70 еллык юбилей, 1995 елда “1941-45 еллардагы батыр хезмәте өчен” медальләре белән бүләкләнә.



## Нуриева (Сафина)
## Мәсерүрә Сафа кызы

1923 елның 5 мартында Саба районы Тенеки авылында туган. 13 яшеннән әнисенә ияреп тылда булган барлык авыр эшләрдә эшләгән.

Тыл ветераны. Бөек Җиңүнең 30, 40, 50, 55, 60, 65, 70 еллык юбилей, 1995 елда “1941-45 еллардагы батыр хезмәте өчен” медальләре белән бүләкләнә.   Хәзерге вакытта исән - сау, Чаллыда яши.





# Хәлилова (Мөбәрәкҗанова)
# Шәмсенур Мөбәрәкҗан кызы

1924 елның 13 февралендә Тенеки авылында дөньяга килә. 1937 нче елда аларның гаиләсе Йосыф-Алан авылына килеп төпләнә. Шәмсенур апа, 4 класс укыганнан соң, әнисенә ярдәм итәргә фермага йөри. Өйдәге кечкенә энеләрен карау да күп вакыт аның өстендә була. Сугыш чыккач, яшь кызны окоп казырга җибәрәләр. Аннан кайтуга, әтисе белән урман кисәргә йөри. Кая кушсалар, шунда тырышып эшли ул. Фермада  бозаулар да карый, сыер да сава. 1952 нче елны Юлбат авылы егете Галиәхмәткә кияүгә чыга. Алар 4 бала тәрбияләп үстерәләр. Сугыш юлларын  үткән Галиәхмәт абый 1979 нчы елда бакыйлыкка күчә.

Бүгенге көндә Шәмсенур апа, һәр туган көнгә шөкер итеп, улы Насих белән килене Зәмфәрия  тәрбиясендә яши. 10 онык һәм 7 оныкчыгын күрү бәхетенә ирешә.

Тыл  ветераны. Бөек Җиңүнең 30, 40, 50, 55, 60, 65, 70 еллык юбилей, 1995 елда “1941-45 еллардагы батыр хезмәте өчен” медальләре белән бүләкләнә.





# Кәшәпова (Мөбәрәкшина) Зәйнәпбикә Мөбәрәкша кызы

1925 елның 15 декабрендә Саба районы Шытсу авылында колхозчы гаиләсендә туа. 4 класс белем ала. Сугыш башланганын кунакка баргач ишеткән, сугыш вакытында урман кискән, юл салган, басуда эшләгән.

Киндердән теккән күлмәк, чалбар, аякта чабата булган. Кычыткан ашы, алабута ипие ашаганнар. Гаиләдән сугышка абыйсын озаткан. Сугыш беткән дигәнне сеңлесенән ишеткән. Аннан соңгы тормышы Шытсуда үткән. Шулай ук урман кискән, юл салган, басуда эшләгән. Күпмедер вакыттан соң, Калатау авылы егете Кәшәпов Нургаянга кияүгә чыгып, дүрт бала тәрбияләп үстерәләр. Эшен колхозда дәвам итә. Хәзерге вакытта малае Фәнил һәм килене белән Йосыф - Алан авылында яши.

Тыл ветераны. Бөек Җиңүнең 30, 40, 50, 55, 60, 65, 70 еллык юбилей, 1995 елда “1941-45 еллардагы батыр хезмәте өчен” медальләре белән бүләкләнә.





# Ибәтуллин
# Мөдәрис Ибәтулла улы

1932 елның 13 июнендә Юлбат авылында крестьян гаиләсендә бишенче бала булып дөньяга килә. Юлбат мәктәбендә дүртьеллык башлангыч белем ала. Сатыш җидееллык мәктәбендә җиде класс белем алып, укуын тәмамлый.

“Бик авыр чорга туры килде безнең балачак. Ашарга җитмәү, өскә кием булмау үзәкләргә үтте,” - дип сөйли Мөдәрис абый.

Сугыш башланганда аңа нибары 9 яшь була. Яшь булуга да карамастан, басуда башак җыйган, ат белән тырма тырмалаган, төнлә ат көтүе көткән. Шәмсетдин бабайга ашлык чәчү өчен, таш белән алдан межа ясап йөрдем, - дип искә ала ул.

Сугыш башланган дигән хәбәрне күршесе этисенә әйткәндә ишеткән. Сугыш сүзен бик аңлап җиткермәсә дә, этисенең йөзеннән куркыныч хәбәр икәнен аңлап алган. Бөек Ватан сугышына этисе, Шәйхулла һәм Кәшфулла абыйлары киткән. Әтисенең күңеле сизенгәндәй, башка кайта алмам дип саубуллашып киткән. Ул Мәскәү астында үлеп кала. Шәйхулла абыйсы контузия алып кайта, ә Кәшфулла абыйсына бары сигез елдан соң гына туган ягына әйләнеп кайту насыйп була.

Бәләкәй генә булса да, аларга да норма үтәү булган. Норма 50 көн. Норма

үтәлмәгәндә, налог түләткәннәр. Нормаларын үтәсәләр, вика оны биргәннәр. Онны өйгә кайтканчы ялап бетерә идем, ди. 1948 елда Сатышта сложный молотилка белән сукканда, ярдәмче булып йөргән. 1949 елда “Саба” колхозында “У-2” тракторында эшләгән. Шул ук елны Арча районы “Үрнәк” колхозына тракторчылар курсында укып, тракторчы кенәгәсе алган.

Аннан кайткач, Хатмулла, Миңлебай абыйлар белән ДТ – 54 тракторында эшләгән.

Мөдәрис абыйның Совет Армиясе сафларына алынуы да бик кызыклы була. Төнге сменадан эштән кайтып яткан гына булган, повесткага менәргә дип хәбәр килгән. 1951 елның 1 октябрендә Армия сафларына алына. Украинада һава пехотасында 3 ел хезмәт итә. 1954 елның октябрендә илгә булган бурычын үтәп туган авылына кайта.

1955 елның 27 мартында Мәртен авылының Рәшидә исемле кызы белән тормыш корып җибәрәләр. Ике кыз, 1 ул үстерәләр. Балаларының барсыда үз гаиләләре белән тигез, матур гомер итәләр.

1965 елга кадәр “Ворошилов” исемендәге колхозда тракторчы булып, пенсиягә чыкканчы “Искра” колхозында тегермәнче булып эшли.
1992 елдан лаеклы ялда. Хәзерге вакытта Юлбат авылында яши.

Тыл ветераны. 1977 елда “Почет билгесе” ордены, Бөек Җиңүнең 30, 40, 50, 55, 60, 65, 70 еллык юбилей, 1993 елда “1941-45 еллардагы батыр хезмәте өчен” ,“В.И.Ленинның 100 еллык юбилее” медальләре белән бүләкләнә.

.





# Ибәтуллина (Габдуллина)
# Рәшидә Габдулла кызы

1932 елның 14 августында Мәртен авылында туа. Гаиләдә дүртенче бала була. Дүрт класс белеме бар. Аның да балачагы бик авыр елларга туры килгән. “Елның нинди вакыты булуына карамастан, көне-төне агач кисүләр, язын чит авыллардан җәяүләп симәнә ашлык ташулар, ачлы-туклы килеш колхоз эшендә бил бөгүләр – барысы үтте минем баштан. Ашарга ризык җитмәде, черек бәрәңге ашаган чаклар да күп булды. Урамдагы мәче борчагы, кычыткан, кузгалак, балтырган җитмәде авыл кешесенә. Барсын ашадык. Яз көне ашарга яраклы бар үлән дә безнең өчен ризык булды. Арыш-бодайның һәр бөртеге бик кадерле иде бит. Колхоз үстергән ашлыкның күп өлеше фронтка озатылды. 200-300 грамм ашлык алган өчен төрмә җәзасы яный иде бу елларда”, - дип башлап җибәрде ул.

Әйе, авылда карт – коры, хатын-кыз һәм балалар кала. Сабый чагын күрми, күпме михнәт, авыр хезмәт татый аның әле өлгереп тә җитмәгән иңнәре. Тормышны алып барырга кирәк: кырда игенен дә игәргә, ач-ялангач та булмаска, сугышка төрле җылы киемнәр дә әзерләргә, гомер буе бетмәс кебек тоелган налогын да илтеп түләргә.

Әтиләре, абыйлары сугыш кырында батырларча көрәшкәндә, алар тылда

әниләре белән үзләрен аямыйча эшләгәннәр.

“Сугыш башланган дигән хәбәрне кемнән ишеткәнемне әйтә алмыйм. Ләкин ул елны басуда ашлыклар, урган учмалар калды. Чөнки эшче көчләр җитмәде. Әтиләр, абыйлар сугышка китте. Бала-чага, хатын-кыз күпме эшли ала инде ул. Басуга чыгып урак та урдык, чәчтек тә. Ә абыйлар тырма тырмаладылар. Әниләргә 25 сутый, безгә 8 сутый иде.

1946-47 елларда Килдебәктә, Сабабашта, Лесхозга барып, агач кисеп, өеп, үлчәп тордык. 6 кубометр эшләсәң, язу бирәләр иде”, - ди.

1948 елда Мөхиппә, Сәкинә апалар белән Йосыф - Аланда урман кисканнәр. Эшнең авырлыгы 16 яшьлек кыз өчен бик авыр булган. Ничек көчебез җиткән, әле җитәрлек ашау бармы,- ди авыр сулап. 1955 елга кадәр “Татарстан” колхозы Мәртен фермасында сарыклар карый.

Сугышка гаиләдән әтисе барган.

1955 елның 27 мартында Юлбат авылы егете Мөдәрискә кияүгә чыга. 3 бала: 1 егет, 2 кыз тәрбияләп үстерәләр.

Хәзерге көндә тормыш иптәше Мөдәрис абый белән тигезлектә, пар канат булып, Юлбат авылында яшиләр.

Тыл ветераны. Бөек Җиңүнең 30, 40, 50, 55, 60, 65, 70 еллык юбилей, 1993 елда “1941-45 еллардагы батыр хезмәте өчен” медальләре белән бүләкләнә.



# Мөбәрәкҗанова (Хәлилова) Гыйльмисрур Гаптехәлил кызы

Юлбат авылының тырыш, уңган, оста тегүче егете Гаптелхәлил Сатыш авылы кызы Сидыкиҗамал белән гаилә корып матур итеп тормыш итә башлыйлар. Тормышларына ямь өстәп, гаиләдә бер-бер артлы дүрт малай һәм бер кыз дөньяга килә: Тимершәех-1919 елда, Мөхәммәтвәли-1921 елда, Галиәхмәт-1925 елда, Сәет-1928 елда, Гыйльмисрүр - 1930 елда. Гаилә башлыгы Гаптелхәлил җир эшкәртә, тегү тегә, ә кышкы айларда өязгә тегү тегәргә чыга.

Малайлар сау-сәламәт, таза булып үсеп, кул арасына керә, эшкә ярый башлыйлар. Тормыш алып барулар күпкә җиңеләя төшә. Төпчек кыз әнисенә өй эшләренә булыша, аның ышанычлы таянычы була. Күп балалы гаилә- көчле гаилә, егетләрнең кулыннан эш килә. Үсеп буй җиткәч, өлкән малайлар Тимершәех белән Мөхәммәтвәлине әтиләре үзе белән өязгә алып йөри башлый. “ Аларның өяздән кайтканнарын бик сагынып, түземсезләнеп көтә идек. Уңышлы елларны ат җигеп, күчтәнәчләр төяп, миңа, сеңелләренә күп итеп бүләкләр алып кайтырлар иде. Алар кайткач, туган –тумача, күрше-күлән җыелышып, шау-гөр килеп чәй эчеп, гапләшеп утырырлар иде, әй күнелле булыр иде шул чаклар,” - дип искә төшерә Гыйльмисрүр әби.

Колхозлашу башлангач, Гаптелхәлилнекеләр беренчеләрдән булып колхозга керәләр. Анда да сынатмыйлар. Елына 1000 хезмәт көне башкара торган була тырыш, уңган егетләр. Эше барның –ашы бар. “ Хезмәт көненә тигән икмәкне “кызыл олау” белән өләшеп китерәләр иде”, - дип сөйли күршеләре Гаптелхәй абый. Шулай матур гына яшәп ятканда, ил өстенә кара афәт булып, фашист илбасарлары ябырыла. Бөек Ватан сугышы башланып китә. “Ул көнне бөтен авыл халкы җыелып, өмә ясап, Чәбки Саба (Чәүкә) башында сәмәннән ферма төзүдә иде. Малай-шалай ыштан балакларын сызганып, кызлар күлмәк итәкләрен кыстырып, ялан аяклап кызыл балчык измәсе изәләр. Өлкәнрәкләр чиләк, носилка белән балчык, вак салам ташый, олылар әзер измәне кысаларга тутырып тора. Көн матур, кояшлы, эш гөрләп бара. Бер мәлне кемдер, карагыз әле, кара, тузан болыты туздырып Сатыш ягыннан берәү атта чаптыра, дип тынычлыкны бозды. Өлкәннәр шөбһәләнеп, бер-бер хәл булдымы икән әллә, бу кадәр ат куаламас иде, дип эшләреннән бүленделәр.
Чапкын безнең янга килеп җиткәч, кисәк тезгенен тартып атын туктатты, ат арт аякларына басты, җайдагы егылып төшә язды һәм ул: “ Сугыш башланган!

Герман сугыш башлаган!” - дип халыкка җиткерде дә, Тенеки, Мәртен авылларына таба чаптырды. Хатын-кызлар елаша башлады, ир-атлар җитдиләнделәр, кулдан эш төште, шунда митинг җыйдылар, фашист илбасарларын тиз арада юк итәчәкбез, җиңү безнең якта булачак дип чыгышлар ясадылар һәм халык авыр хәсрәттә өйләренә таралды. Шушы көннән бала чакның рәхәтлеге бетәсен без белми идек әле, - дип искә ала Гыйльмисрүр әби.

Икенче көнне үк авылдан ир-егетләрне сугышка озата башладылар. Алар артыннан яхшы, көр атларны да алып киттеләр. Шулай итеп, авылдагы барлык бетмәс-төкәнмәс эш картлар, хатын-кызлар һәм бала-чага җилкәсенә өелеп калды. Урак уру,басудан чиләк тотып башак җыю, көлтәдән кибән кую, эскерт салу, кул белән киндер, җитен йолку (чөнки алар кыска булып үсәләр иде), икмәк сугу машинасын кул белән әйләндерү, кышын keләт эчендә тартма белән икмәк күчерү, каравыл өендә капчык ямау һәм тагын бик күп төрле эшләр башкарырга тры килде шул чор балаларына. Иштуган һәм Шәмәрдән станцияләрендә вагоннарга озын-озын бүрәнәләр төядек. Урманнан ат белән тарттырып алып чыгарлар иде, без шуларны агачтан тәгәрәтеп вагоннарга төйи идек. 13-14 яшьлек кызларның ничек көче җитте икән шуңа дип шаклар катып утырам хәзер. Тору квартираларда иде, авылдашлар бергәләшеп тора идек.Өстебездәге киемнәр матрас та булды, юрган ролен дә үтәделәр. Анда сиңа беркем дә урын-җир әзерләп куймаган. Эштән кайтканда, һәрберебез өйне җылыту өчен, берәр утын пүләне күтәреп кайта идек. Ашату юк, үзең белән өйдән кем нәрсә алып килә ала, шуның белән туклана идек. Ашарга ризык беткәч, атка төялеп, авылларыбызга кайтып китәбез. Яңадан ипи салып, ашарга юнәтеп, кабаттан килә идек. Бер партия кайта, икенчесе килә. Шулай чиратлап эшләдек. Юлбат кешеләре Шәмәрдәндә Кашаф дигән кешегә квартирага туктала идек.

Сугыш еллары авыр хезмәт белән, ачлы-туклы тормыш белән безнең бала чакны урлады. Без вакытыннан алда өлкәнәйдек. Матур истәлекләр истә калмаган да. Бер-бер артлы өч абыем сугышка китте, Сәетгәрәй абыйны ФЗӨ га алдылар, сугыш башланган елны әтием вафат булды. Әни белән миңа бик авырга туры килде. Ничек түзгәнбездер, бер ходай үзе генә белә. Ике абыем сугышта һәлак булдылар, өченчесе 1946 елны гына кайтты. Сугыштан соң да тормышлар тиз генә рәтләнмәде әле. 1951 елда бер төркем авылдашлар белән Киров өлкәсенә вагоннар төяргә җибәргәннәре истә калган. Баракларда яшәдек, анда төрле авыллллардан, төрле милләт вәкилләре җыелган иде. Ул вакытта урманнан агачларны тракторлар белән чанага төяп алып чыгалар иде инде. Тракторлар урманнан чыккач, көннең кайсы вакыты, һава торышы нинди булуга карамастан, шау-гөр килеп, аларны бушатып вагоннарга төйи идек.

Чөнки тракторларны бер генә минутка да тоткарлап торырга ярамый. Октябрь аенда киткән идек, 6 нчы апрельдә генә кайттык. Без кайтканда, көннәр җылыткан, юллар беткән. Сабадан Тенеки аша кайттык, Хәйбрахманнар елгасыннан көчле су ага, чыга торган түгел. Камалетдин абыйның хатыны Миңлебикә, күршеләре белән такта салып, безне чыгарды. Без юкта Камалетдин абый өйләнеп куйган. Авылдан Сәләхов Сәет белән хатыны Мәхтүмә, Тимер Харисе, Мәҗит Тәгъзимәсе бергә идек. Кировтан кайткач, сарыклар фермасына эшкә билгеләделәр. Анда Фәрхулла кызы Саимә, Рәхматулла кызы Тәкминә, Нургали кызы Рабигалар белән бергә эшләдек. Ул елларда атлар юк дәрәҗәсендә, булганнары да арык.

Безнең чор кешесенең бер эшләмәгән эше калмады. Ничек түзгәнбездер, хәзер шаклар катып уйлап утырам. Ләкин беребез дә зарланмый торган иде. Хәзерге заман тормышы белән чагыштырам да, хәйраннар калам. Шундый рәхәт, мул, бай томышта яшибез, кадерен генә белегез, безнең чор кешесенең төшенә дә кергән әйберләр түгел бит бу. Без үскәндә туйганчы бер ипи ашасаң иде ул, дип хыяллана идек. Аллага шөкер бу көннәрне дә күрдек. Илләребез тыныч, күкләребез аяз, бәндәләр сугыш афәтләре,ачлыкны, юклыкны

кайтабыз, тиресне чаналарга төяп, үзебез басуга түгә идек. Ул елларда үгезләр дә җигелеп, халыкка хезмәт итте. Урманнан сарыкларга миллек хәзерләп, үгезгә төяп алып кайта идек. Нотфулла абый, үгез җигеп, фермага бәкедән су тутырып ташый иде. Бер төркем хатын-кызлар белән уфалла арбасына икмәк төяп, Түбән Шытсу авылы тегермәненә ферма малларына фураж тартырга барган истә калган.Үзебезнең тегермән ватык булгандыр инде. Шәмәрдәннән арба тартып, симәнә алып кайтулар күп булды инде. Бер арбада ике капчык икмәк, шуны ике кеше бергә тартасың. Кул арбасы белән тартып, Сабага май заводына хуҗалыктан җыелган сөтне меңгезә идек. Иртүк кузгалырга кирәк, көн кызуланганчы, алайса сөт әчи.

Безнең чор кешесенең бер эшләмәгән эше калмады. Ничек түзгәнбездер, хәзер шаклар катып уйлап утырам. Ләкин беребез дә зарланмый торган иде. Хәзерге заман тормышы белән чагыштырам да хәйраннар калам. Шундый рәхәт, мул, бай томышта яшибез, кадерен генә белегез, безнең чор кешесенең төшенә дә кергән әйберләр түгел бит бу. Без үскәндә, туйганчы бер ипи ашасаң иде ул, дип хыяллана идек. Аллага шөкер, бу көннәрне дә күрдек. Илләребез тыныч, күкләребез аяз, бәндәләр сугыш афәтләре, ачлыкны, юклыкны күрмәсеннәр иде диеп телим Ходайдан. Тормышның кадерен белегез!”

Тыл ветераны, Бөек Җиңүнең 30, 40, 50, 55, 60, 65, 70 еллык юбилей, 1995 елда “1941-45 еллардагы батыр хезмәте өчен” медальләре белән бүләкләнә.



# Шакирҗанова (Шәйхелисламова) Корбанбикә Шәйхелислам кызы

Әнием - 1931елның 25 мартында Юлбат авылында крестьян гаиләсендә дөньяга килә. Юлбатта башлангыч сыйныфта 4класс, Сатыш җидееллык мәктәбендә 7класс белем ала. Сатыш мәктәбенә укырга төшеп киткәнче, кул чанасы белән Йосыф-Алан урманыннан ягарга утын алып төшүләрен дә хәтерли.

“Сугыш башланган” дигән яман хәбәрне әнисе Фәгыйлә басудан ишетеп кайта. Дөрес, алар гаиләсеннән сугышка чыгып китүче булмый, чөнки әтиләре Шәйхелислам өлкән яшьтә, ә абыйсы Мөбәрәкҗан 13 яшендә генә була.

Әни хезмәт юлын колхозда бик яшьли башлап җибәрә. Юлбат амбарыннан (ул вакытта глубинка дип аталган) кечкенә янчыкка салынган чәчүлек орлыкның сыйфатын тикшертү өчен, Сабага лабораториягә алып менеп йөри. Соңыннан амбарга икмәк үлчәүче итеп тә куялар. Күрәсең, җиде класс белемем дә, эшкә таза булуым да ышаныч тудыргандыр дип искә ала ветеран.

Яшь кызны өлкәннәргә ияртеп, Иштуган станциясенә вагон төяргә җибәргәннәр. Яшен белгәч, бу эшнең җитәкчесе, өстенә җаваплылык алудан куркып, кайтып китәргә куша. Авылга кайткач, колхоз рәисе яшен әйткән өчен ачулана, чөнки колхозның бик авыр еллары, бар хезмәт хатын-кыз, бала-чага җилкәсендә дип сөйләп китә. Эшче сорап, көн дә колхозларга наряд килә, үтәми кара, илгә хыянәтче дип, җитәкчеләрне хәзер җавапка тартачаклар.

Өлкәннәр белән лобогрейкада эшләгән вакытлары да гел хәтерендә саклана аның. Басудан кайтмый эшләүләр, әниләрнең төенчеккә төйнәп ашарга алып килүләре дә онытылмый дип искә ала. Төнлә чүмәлә өстенә башны куеп, 2-3 сәгать йокы белән канәгатьләнергә туры килә ул вакытларда. Кыр эшләре беткәннән соң, колхоз идарәсендә хисапчыга ярдәмгә табельщик булып та эшли.

Сугыштан соңгы елларның да бик авыр булуын искә ала әнием. Эш авыр, ачлы-туклы тамак белән үткән яшьлекләре кызганыч, әлбәттә. Аннан дуңгыз фермасына эшкә куялар. Дуңгызлардан бик курыкканга, алар янына кермичә, шуларны караучы өлкән яшьтәге хатын-кызларга олы чиләкләр белән апара ташырга ризалаша.

1950-54 нче еллар аралыгында авылдагы сельпо кибетенә сатучы булып керергә туры килә, чөнки анда эшләгән Сәйфуллин Мөхәммәткә армиягә китәргә повестка килгән була. 1953нче елда шушы авыл егете фронтовик Шакирҗанов Гайфетдин белән гаилә корып җибәрәләр. Өч ир бала (берсе сабый вакытта ук авырып үлеп китә) һәм бер кыз үстерәләр. Кызганычка каршы, кабат бала хәсрәте кичерергә туры килә аңа. 23 яшьлек улы Нәфыйк тракторы белән эш вакытында фаҗигагә очрап вафат була.

Әнием 1970 нче елга хәтле колхозда эшли. Ә 1970 нче елдан лаеклы ялга чыкканчы Юлбат һәм Тенеки авылларында почтальон хезмәтен башкара. Ул вакыттагы газета-журналларның күплеген сөйләп бетерерлек түгел, ди. Һәр көн иңенә авыр сумка асып, ике авылны әйләнә. Шуның өстенә хат-открытка, йорт саен пенсия таратулар... Шулай да эшен җиренә җиткереп башкара, фотосурәте гел Почет тактасында булуы да шуңа дәлил. 1986 нчы елдан лаеклы ялга чыга. Тик менә тигез картлыкта яшәргә генә насыйп булмый шул: 62яшендә тол кала.

Хөкүмәтебез тыл һәм сугыш ветераннарының ул авыр чорлардагы хезмәтен югары бәяләгән. Әни Россия Федерациясе Президенты Указы белән Бөек Җиңүнең 50, 60, 65, 70еллыгы юбилей медальләре белән бүләкләнә. 1993 елда “За доблестный труд в Великой Отечественной войне 1941-1945гг.” медаленә лаек. Шулай ук Татарстан Республикасы Президенты исеменнән 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 55 еллыгы хөрмәтенә Татарстан Республикасының истәлек билгесе белән бүләкләнгән.

Бүгенге көндә 85 яшен тутырган әниебез бөтен уңайлыклары булган йортта яши. Сугыш ветераннарының тол хатыннарына дәүләт салып биргән заманча, якты йорт ул. Балачагы, яшьлеге авыр сугыш елларына туры килсә дә, ветеран бүгенгесе өчен бик шөкер итеп, балалары, оныклары ихтирамын тоеп, тормышыннан бик риза, канәгать булып яши. Һәркөн илләребезгә иминлек, табыннарыбызга муллык, һәммә кешегә хәерле гомер теләп дога кыла. Туган нигезнең җылысын суытмыйча, безне көтеп алып, озатып калучы әниебез булганга, без бик бәхетле. Хәзерге вакытта Юлбат авылында яши.





# Хәлилова (Вәлиева) Мәүлиха Шәмси кызы

1932 нче елның 18 мартында Татарстан АССРның Саба районы Орымширмә авылында ярлы крестьян гаиләсендә туа. Шул авылда башлангыч белем ала. Мәүлиха апаның бабасын кулак дип, бөтен булган әйберләрен алып урамга куып чыгарганнар. Бер өйләре озак еллар мәктәп вазыйфасын башкарган. “Без шунда укыдык,” – диде Мәүлиха апа.

Алар сугыш башланганчы, Эрбет дигән җиргә киткән булганнар. Сугыш башланганын шунда ишеткәннәр. Әтисе, сугышка киткәнче дип, гаиләсен авылга кайтарып куйган. Үзе сугышка киткән. “Ике тапкыр үлгән дигән хәбәре килде,” – ди Мәүлиха апа. Әтисе Шәмсемөхәммәт каты яраланып госпитальгә эләгә һәм 3 елдан соң сугыш өчен яраксыз дип өенә озатыла. Шулай ук сугышка әтисенең энесе Сәетгали абыйсы да киткән. Сугышка киткән көннән алып, абыйсыннан бер хәбәр дә килмәгән. Бертуган абыйсы Мәгъсүмне ФЗӨ га алып киткәннәр. Ул шахтада эшләгән. Сугыш елларында тормышлары бик авыр булган. Ашау- эчү булмаган. Кычыткан, черек бәрәңге җыеп ашаганнар. Киндер сугып киенгәннәр, чабата үргәннәр. “Бу елларда колхозда нинди авыр эшләр бар, барсын да эшләдек. Башта яшьрәк вакытта чүп утарга бардык, аннары басуда кар тоттык, соңрак урман кисүдә катнаштык. Үгез җигеп, көлтә һәм агач ташыдык, “ – диде Мәүлиха апа. Кичке уеннар, аулак өйләр булган. Ач булсалар да, кичләрен сукыр лампа яндырып күңел ачканнар, кул эшләре эшләгәннәр.

“Сугыш бетте дигән хәбәрне авылда хатын-кызлардан ишеттем,” - диде ул. Сугыштан соңгы елларда тормышлары шулай ук бик авыр булган. Әтиләре авырган, аны әниләре караган. Ул 1949 нчы елның 14 апрелендә вафат булган. Әниләре алты баланы карап тәрбияләгән. Ләкин үзе дә бик авырган. Шулай итеп тормыш яшь 16-17 яшьлек Мәүлиха апа җилкәсенә калган. Колхозда эшләгән. Машинада грузчик булган, урман кисеп, шуны үзләре арбага төяп алып кайтканнар. Кыш буе Лаеш урманында урман чистартуга җибәргәннәр.

Шулай итеп тормыш яшь 16-17 яшьлек Мәүлиха апа җилкәсенә калган. Колхозда эшләгән. Машинада грузчик булган, урман кисеп, шуны үзләре

арбага төяп алып кайтканнар. Кыш буе Лаеш урманында урман чистартуга җибәргәннәр. Алар урманда шалашта яшәгәннәр. Ашарга-эчәргә булмаган, бик суык булган. Шулай ук төрле авылларда да булганнар. “Бик еракка Малатов урманын кисәргә дә бардык әле без,” – дип сөйләде Мәүлиха апа.

1957 елның июнь аенда Юлбат авылы егете Хәлилов Сәетгәрәйгә тормышка чыга. Аның белән бергә 4 бала (2 ул һәм 2 кыз) тәрбияләп үстерәләр. Ул колхозда төрле эшләрдә эшләгән: ындыр табагында, басуда көлтә бәйләүдә, ашлык сугуда, бәрәңгедә, ашлык агулауда. Бүгенге көндә бер улы белән төп йортта тыныч кына гомер кичерә. Балалары әниләре янына гел кайтып йөриләр. Мәүлиха апа аларның уңышларына, оныкларының, оныкчыкларының бәхетенә сөенеп яши бүгенге көндә.

Тыл ветераны, Бөек Җиңүнең 30, 40, 50, 55, 60, 65, 70 еллык юбилей, 1993 елда “1941-45 еллардагы батыр хезмәте өчен”, “Ударник девятой пятилетки” медальләре белән бүләкләнә. Юлбат авылында яши.

Мәүлиха апа шул авыр еллар турында шигырьләр дә иҗат иткән. Шуларның берсе язып алынды.



**Сугыш афәте.**

Без үскәндә күрдек инде
Дөньяларның төрлесен.
Алга таба ни күрербез
Белеп булмый дөресен.
Тормышның авырына.
Печәнен чаптырдылар, урагын урдырдылар
Төннәләрдә лачинкәләп көлтә җыеп
Кибәнен куйдырдылар.
Урманын кистерделәр,
Вагонын төяттеләр.
Сез яшь дип тә тормадылар
Эшләргә өйрәттеләр!
Ашау нәрсә әле?
Черек бәрәңге ашадык.
Язга чыккач симәнәне
Кутушкалап ташыдык.
Аякта оек – чабата,
Суык аякларката.
Моны сөйләп күрсәтсәң,
Хәзер яшьләр шакката.
Чабата кигән кешеләр
Хәзер аяксыз ята.



# Кәбирова (Латыйпова) Минҗиһан Шәкүр кызы

Кызыл Мишә авылының Шәкүр белән Мөхипҗамал гаиләсендә беренче бала булып, 1923 елның 3 нче октябрендә Минҗиһан исемле кыз дөньяга килә. Әтисе оста итек басучы була һәм, көз айлары якынлашкач, бер төркем ир-атлар Башкортстан якларына итек басарга чыгып китә торган булалар. Ә әнисе колхозда төрле эшләрдә эшли. Шулай ук әнисе, укымаса да, мал табибы буларак, кешеләргә ярдәм итә.

“Әнинең яңадан ике энекәше була : берсе Миннәхмәт, икенчесе Нурәхмәт. Нурәхмәт Ерак әби ( без әнинең әнисен шулай атый идек) эштә вакытта казандагы эссе суга пешә һәм шуннан терелә алмыйча үлә. Энесенең азаплануы йөрәгенә тиеп калгангадыр инде, безгә гел” пешә күрмәгез” дип кисәтеп килде. Аларның өйләре, елга аша чыгып, тау башына салынган була. Аннан алар авыл уртасына күченәләр, ләкин алар алган йорт гел су эчендә утыру аркасында, киредән элекке урыннарына кайталар. Әнинең әтисе, Башкортстан якларында итек басканда, үпкәсенә салкын тидереп кайта һәм авылга кайткач, анннан терелә алмый. Шулай итеп, тормышның бөтен авырлыгы өлкән бала булган әни җилкәсенә төшә. Ерак әби белән икесе тау башы урамында йорт җиткереп чыгалар. Нинди генә авыр вакытлар булса да, әни Тимершык мәктәбендә 7 класс белем ала. Математика фәнен бик яратып укый. Гомеренең ин гүзәл вакыты - 17 яшь тула. Матур хыяллар дөньясында очынып йори ул. Ләкин, бөтен хыялларны жимереп, сугыш башлана ...... Әнине һәм тагын авылдан берничә кызны Киров якларына урман кисәргә җибәрәләр. Ана нибары 17 яшь була.... Аларны квартирага бер бабайларга урнаштыралар. Квартира хуҗалары акыллы кешеләр була. Алар әнине ач итмәскә тырышалар.

”Ул кискән агачларны ат арбасына төяп, тимер юл станциясенә чыгара идек һәм вагоннарга төйи идек. Аяктагы чалма белән чабата юешләнеп бетә, үтереп тамак ача. Ничек суык тимәгән”, -дип, гел безгә сөйли иде хәтере яхшы вакытта.

Урман кисү туктаганнан соң, авылда берничә ел фермада эшли, 18 сыер сава. Әни эшкә бик батыр, тырыш була. Шуңа күрәдер инде бераздан аңа атлар карарга кушалар. Әнинең бөтен яшьлеге авыр хезмәт белән үтә. Сугыш беткән көн ин бәхетле көн була...

1956 елда әнине димләп, Юлбат авылының Сәетгали исемле кешегә кияүгә бирәләр. Әни, әтигә кияүгә чыккач кына, авыр хезмәттән бераз арындым дип шатлана, чөнки монда килгәч, аңа ирләр эшен башкарырга туры килми. Әтиләр гаиләсе, бай булмаса да, ныклы тормыш белән яшәгәннәр. Әни төп йорт килене була. Алар башта әби, бабай, әтинең 3 ир туганы бергә яшиләр. Әни бик тырыш, чиста, пөхтә була, тәртипне ярата, кичләрен оекбашлар, бияләйләр бәйли, абзар тутырып мал асырыйлар. Нинди генә эштә эшләсә дә, эшен ахырына кадәр башкарып чыга белә. Кияүгә чыккач, әни төрле эштә хезмәт куя: басуда кар тоту, салам өю, көлтә бәйләү, кишер, чөгендер, бәрәңге басуларында , яшелчәчелектә, ындыр табагында эшләү белән бергә, 3 бала – бер кыз, ике малай тәрбияләп үстерәләр. Аларга югары белем биреп, гаилә корып җибәрергә ярдәм итәләр. Хәзерге вакытта әни улы Васил һәм килене Гөлсинә тәрбиясендә хөрмәттә яши. Әни, энем Васил, киленебез Гөлсинә төп нигезне тотып, туганнарны барлап торалар. ”Ярый әле үзем генә яшәмим, “-дип һәр көненә шөкер итә әни.

Сугыш елларындагы хезмәтләре өчен хөкүмәтебез әнине сугыш бетүнең 45, 50, 60, 70 еллыгына, 1993 елда “1941-45 еллардагы батыр хезмәте өчен” медальләре белән бүләкләде. Гомумән, бу чор балаларын нинди генә бүләкләр белән бәяләсәк тә бәяләп бетереп булмас иде. Алардагы сабырлык, тырышлык, түземлек, хезмәт сөючәнлек Аллаһа тәгалә тарафыннан бирелгән байлыктыр ул.

Кызы Сәлимә апа сөйләгәннәрдән.



# Әхәтова
# Нурия Әхәт кызы

1928 нче елның 13 мартында (Кыз фамилиясендә калган) Саба районы Юлбат авылында туган. Әтисе Габделәхәт (Юлбат кешесе), әнисе Мофаззала (Килдебәк авылыннан). Нурия апа колхозчы гаиләсендә абыйсы Нурлыәхмәттән соң икенче бала булып дөньяга килә. 4 класс белем ала.

1941 елда әтиләре Донбас шәһәренә эшкә чыгып китә. Барып урнашкач, хатынын (Нурия апаның әнисе), һәм ике баласын да үзе белән Донбаска алып китә. Өч ай яшәгәннән соң, сугыш башлану турында хәбәр килә. Бөтен җирдә радио сөйли. Әниләре, иртүк уятып, сугыш хакында аңлата. “Ул көн хакында тыныч кына сөйләп тә булмый, елау, ыгы-зыгы иде,” -дип искә ала Нурия апа. Дошман инде якында гына, ул яшен тизлеге белән якыная. Халыкны мобилизацияләү башлана. Әтиләре аларны, Юлбатның Ногман исемле кешесенә ияртеп, туган якларына кайтарып җибәрә.Үзе шахтада эшләп кала, шуннан соң сугышка алына.

Авылда Нурия апаларны буш өй каршы ала. Күченеп киткәч, бәрәңге дә утыртылмаган, ашарга ризыклары да булмый. Әниләре Мофаззала апаны 3 айга Апас районы Йомран авылына окоп казырга чыгарып җибәрәләр. 13 яшьлек Нурия апа, 14 яшьлек Нурлыәхмәт абый өйдә берүзләре генә калалар. Нурлыәхмәт абыйсын иртәнге якта Сатыштан почта алып менү эшенә, аннан соң тегермәнгә исәпләү эшенә куялар. Ә Нурия апа кышын тегермәндә ашлык сүктыруда эшли. Яз җиткәч, кара көзгә кадәр басу эшендә эшлиләр, кыш көне яңадан ашлык сугу (молотилкага башак биреп торалар) эшендә эшләвен дәвам итә. 15 яшендә абыйсын Магнитогорскига трудармиягә алалар. Нурия апаларны үзләре кебек 14-15 яшьлек кызларны, Яшел Үзән шәһәреннән 150 км ераклыктагы заводта (ФЗӨ) станок артына бастыралар. Балаларга аз булса да

ашату була. Бер эш артыннан икенчесе башланып кына тора. Октябрь – март айларында урман кисү башлана.

Яшь кенә кыз балалар, авырлыкларга түзә - түзә, бик тырышып эшлиләр. Март аенда урман кисүнең иң авыр вакыты: вагон төяү башлана. 3 метрлы агачларны җилкәләренә китереп салалар. Агачларны вагонга алып барганчы хәйран гына ара барырга кирәк. Әкрен булырга ярамый, ачуланалар. “Вагонннар күпме килсә, шуның кадәр төяргә кирәк,” - ди Нурия апа. Әтиләре сугыштан яраланып кайта, бераз савыккач, яңадан трудармиягә алалар. Сугыш беткәнче, Мурманскида әсирләргә урман кистерүдә эшли.

Сугыш бетте дигән хәбәрне авылда ишетәләр, шатлыклы мизгелләр кичерәләр. Җиңү бәйрәмен чишмә буенда, зур казан белән ботка пешереп бәйрәм ясыйлар. Сугыштан соң да авыр хезмәт дәвам итә. Тенекидән Сабага кадәр юл төзүдә, Мамалай күперен эшләүдә, Кукмара, Балыклы районнарында юл төзүдә эшлиләр.

Кичке уеннарга чыгалар. Сайфуллина Гүзәлләр нигезендә клуб була, шул клубта төрле уеннар уйныйлар.

1960 елда Сәет абый армиядән кайта. 1961 елда Рахматуллин Сәет абый белән никах укыталар. Уллары Илфир дөньяга килә.

Нурия апа гомер буе колхозда эшли. Плугар (трактор артында суканың тирәнлеген карап йөрүче), комбайн ярдәмчесе булып та, кыр эшләрендә дә эшли Нурия апа.



Бүгенге көндә Сәет абый белән уллары Илфир, киленнәре Гөлназ тәрбиясендә тигез гомер кичерәләр. Нурия апа үзенә бирелгән медальләрен, мактау кәгазьләрен еш кулына ала. Менә алар: Тыл ветераны, 1995 елда “1941-45 еллардагы батыр хезмәте өчен”, Бөек Җиңүнең 30, 40, 50, 55, 60. 70 еллык юбилей медальләре.

Нурия апа туар көннәрнең тыныч булуын тели. Яшь буын алар күргән авырлыкларны күрмәсеннәр дигән теләк белән яши. Без яшь буын исә, әлеге ветераннар белән горурланып яшәргә тиешбез.

# Габдрахманов Мөхәммәтюныс Габдрахман улы

1929 нчы елның 28 маенда Мөбәрәкшин Габдрахман семьясында 5 нче бала булып дөньяга килә. 1937 елда мәктәпкә укырга керә, 4 класс белем ала.
1940 елда колхозда төнлә ат көтә, көндез колхозда төрле эшләрдә катнаша. 1952 елда Совет Армиясе сафларына алына. 2 елын Төньяк Корея, 1955 елга кадәр Омск шәһәрендә, Чита өлкәсендә хезмәт итә. Армиядән кайткач, колхозда, промкомбинатта эшен дәвам итә.

Мөхәммәтюныс абый тормыш иптәше Рәкига апа белән биш бала: 3 кыз, 2 ул тәрбияләп үстерәләр. Хәзерге вакытта улы Назиф, килене Фәрхәнә семьясында гомер итә. Тенеки авылында яши.

Тыл ветераны, 1947 елда “1941-45 еллардагы батыр хезмәте өчен”, Бөек Җиңүнең 30, 40, 50, 55, 60, 65, 70 еллык юбилей медальләре белән бүләкләнә.



# Сафин
# Раян Галәветдин улы

Минем бабаем, Сафин Раян Галәветдин улы, 1930 нчы елның 1 октябрендә туа. Сугыш башланганда, аңа нибары 11 яшь кенә була. Ул елларда 2 нче сыйныфта укыган чаклары була. Авылда карт-карчыклар белән бала-чага гына кала. Ә колхозның эш арбасына җигелеп бөтен авыр хезмәтне башкару бабаемнар кебек балалар җилкәсенә төшә. Дәһшәтле сугыш еллары бабаемның иң күңелле, самими балачак елларын урлый. Кышларын ат җигеп ат торагында эшли, басудан көлтә ташый. Яз җитеп, кырлар кардан арчылгач, иптәшләре белән басуга чәчүлек җирләре хәзерләргә баралар. Ат җигеп, тырма тырмалыйлар. Җәй урталарында чалгы тотып, печән чабарга китәләр. Күп тапкырлар урманга агач кисәргә барулары да, авыр еллар кайтавазы булып, хәтерендә саклана. Ә шулай да бабаем зарланмый. Бер гөнаһсыз сабый йөрәгендәге фашистларга булган үче авырлыкларны җиңеп чыгарга көч-куәт бирә.

Сугыш вакытында колхозның акчасы бетә. Бабаемның абыйсы Тимерҗан ул вакытларда бригадир булып эшли. Колхоз председателе Хәй абый, клуб гармунын сатып, акча ясыйк дигәч, Тимерҗан бабай 3 меңгә үзенә сатып алып кайта. Тик ул бабаема гармунда уйнарга рөхсәт итми. Унбер-унике яшьлек шук малай абыйсыннан яшереп уйнарга өйрәнә. Кичләрен яшүсмерләр су буйларына, тыкрык башларына вечерларга җыелалар. Күбесенең аякларында чабата, ә кайберәүләр хәтта яланаяк та булганнар. Зурраклар бер төркем, яшьрәкләр икенче төркем булып утырганнар. Бабаема, авылларында бердәнбер гармунчы буларак, ике төркемдә дә уйнарга туры килгән. “Абыйлар янында бераз уйнагач, тизрәк үзебезнекеләр янына китә идем! Әле колхоз председателе килеп, кызларны ачуланып, иртә белән егетләрнең эшкә чыгасылары бар, озак



тормагыз дип ачуланып китә иде,”- ди ул. Нинди генә сынаулар күрсә дә, бабаем, Аллага шөкер, исән-сау. Безне, оныкларын, тәрбияләүгә зур өлеш кертә. Быелгы яз туган җиребезгә Җиңүнең 71 еллыгын алып килә. Без 71 ел инде тыныч күк йөзе, якты кояш белән бәхетле көнебезне каршылыйбыз һәм без моның өчен сугыш һәм тыл ветераннарына бурычлыбыз. Үткәннәрне онытырга беркемнең дә хакы юк!

Илебезнең ачы язмышын үз иңнәрендә күтәргән халкыбызның фидакарьлеген онытмыйча, якты истәлек итеп саклыйк.

Тыл ветераны, 1948 елда “1941-45 еллардагы батыр хезмәте өчен” медале, Бөек Җиңүнең 30, 40, 50, 55, 60, 65, 70 еллык юбилей медальләре белән бүләкләнә.



## Шәйхелисламова (Әхтәмова) Сәкинә Әхтәм кызы

1929 елның 29 октябренда Мәртен авылында туган. Гаиләдә 5 бала булган. Белеме - 3 класс. Сугыш башланган дигән хәбәрне әнисеннән ишеткән. Сугышка беренче елны ук олы абыйсы киткән һәм шул елны һәлак тә булган.

“Сугыш беткән дигән хәбәрне радиодан ишеттек,” - дип сөйли Сәкина апа. 12 яшеннән урман кискән, вагон төягән, кыр эшләрендә эшләгән.

24 яшендә Юлбат авылы егете Шәйхелисламов Мөбәрәкҗан абый белән гаилә корып, биш бала тәрбияләп үстергәннәр.

Хәзерге вакытта төпчек улы Рузит белән гомер итә.

Сәкинә апа гомер буе “Искра” колхозында эшләде. Колгозга куйган тырыш хезмәтләре өчен авыл һәм район почет тактасыннан карточкасы төшмәде. Сәкинә апа - дәүләт өчен зур хезмәт куйган шәхес.

Тыл ветераны. 1993 елда “1941-45 еллардагы батыр хезмәте өчен” медале, Бөек Җиңүнең 30, 40, 50, 55, 60, 65, 70 еллык юбилей медальләре белән бүләкләнә.

Хәзерге вакытта илебезгә тынычлык теләп, 5 вакыт намазын калдырмый, тыныч кына гомер итә. Юлбат авылында яши.

## Рәхимҗанова Мөнәвәрә Рәхимҗан кызы

1930 елның 1 декабрендә Тенеки авылында эшче гаиләсендә туган. 4 класс белемле. Колхозда эшләгән, агач кискән, көлтә бәйләгән, юл эшләрендә эшләгән. Соңгы елларда май заводында эшләп, лаеклы ялга чыккан.

Тыл ветераны. 1995 елда “1941-45 еллардагы батыр хезмәте өчен”, Бөек Җиңүнең юбилей медальләре белән бүләкләнгән.

Хәзерге вакытта Тенеки авылында яши.

# Фәттахов
# Зиннур Борһан улы



1931 елның 10 апрелендә Йосыф-Алан авылында туганмын. Белемем - 7 класс. Хезмәт юлым ат торагында ат караучы булып эшләүдән башланды. Соңрак тырма, сука белән җир эшкәрттем.

1951-1954 елларда Совет Армиясе сафларына алындым. Ерак Камчаткада чик сакчысы булып хезмәт иттем.

1954-55 елларда Казанда ТЭС-2дә грузчик, 1955-56 елларда УМСХ курсанты.

1956 елдан башта МТС, аннан соң колхозда комбайнчы булып эшләдем. Колхозда булган барлык төр эшләрдә дә катнашырга туры килде.

1991 елда лаеклы ялга чыктым. Ләкин ялда булсам да, 2 елга якын Мусин Габделбәр белән ат чаналары, трактор арбалары ремонтладык.

1956 елның маенда Фәттахова Сания белән гаилә кордык. Өч бала: 2 ул, 1 кыз тәрбияләп үстердек. Балаларыбыз барсы да белем алып, үз юлларын таптылар. Хәзерге вакытта улыбыз Илдар, киленебез Рәшидә тәрбиясендә, бик бәхетле пар канат булып, Йосыф - Алан авылында яшибез.

Тыл ветераны, 1995 елда “1941-45 еллардагы батыр хезмәте өчен” медале, Бөек Җиңүнең 30, 40, 50, 55, 60, 65, 70 еллык юбилей медальләре белән бүләкләндем.



# Фәттахова (Нуретдинова) Сания Нуретдин кызы

1931 елның 8 февралендә Йосыф - Алан авылында туганмын. Гаиләдә җиде бала, мин өченчесе. Миңа 10 яшь булганда, сугыш башлана. Әтиемне Комар урманында утын кискән җиреннән алып китәләр, аның бер генә хаты килә. Соңыннан хәбәрсез югалганнар исемлегендә дигән хәбәр алдык.

Мине 12-13 яшьләрдә фермага эшкә куйдылар. Анда тавык, сарык, сыерлар бар иде. Колхозга нәрәт килгәч, мине, 20 яшьлек кызны, Кемерова өлкәсенә эшкә җибәрделәр. 2 ел эшләп кайттым. Сабада крахмал заводында эшләдем. Җәйгә чыккач, Шәмәрдән-Курсабаш станция аралыгында юл төзүдә катнаштым. Тагын колхозга нәрәт килгәч, Мәскәү астына шахта чистартырга җибәрделәр. Шахта авызы казыдык: диаметры 7 метр, тирәнлеге 7 метр. Бетон заводында раствор ясап тордык, плитәләр ясадык.

1956 елның май аенда Фәттахов Зиннур Борһан улы белән тормыш кордык. 3 бала тәрбияләп үстердек. Улыбыз Илдар Юлбат авыл хуҗалыгында механизатор, кызыбыз Диләрә сәламәтлек өлкәсендә эшләп лаеклы ялда, улыбыз Илсур Казан шәһәрендә гаиләсе белән яши һәм эшли.

Мин, пенсиягә чыкканчы, “Искра” колхозында эшләдем.

1981 елда лаеклы ялга чыктым.

Тыл ветераны, 1995 елда “1941-45 еллардагы батыр хезмәте өчен” медале, Бөек Җиңүнең 30, 40, 50, 55, 60, 65, 70 еллык юбилей медальләре белән бүләкләндем.

Бүгенгесе көндә улыбыз Илдар, киленебез Рәшидә тәрбиясендә Йосыф - Алан авылында яшибез.



# Мәрданова (Фәррахова) Мәдинә Фәррах кызы

1931 елның 26 нчы гыйнварында, хәзерге Теләче районы Орымширмә авылында, колхозчы гаиләсендә туа. Әтисе - Фәррах, әнисе – Гайшәбану колхозчылар була. Алар биш туган – Мәдинә апа, абыйлары Әгъләм һәм Кәшфи, апасы - Нәсимә һәм энесе Фәнил.

Сугыш башланганда, Мәдинә апага 10 яшь була. Бу хәбәрне кайда, кемнән ишеткәнен ул инде хәзер ачык кына хәтерләми. Ләкин олылырның бик борчылганнарын, елашканнарын исендә калдырган. Әтисе карт була, аны сугышка алмыйлар. Ул гел урман кисәргә йөргән, бер китүдә өчәр ай кайтмыйча эшләгәннәр. “Үзем дә шул вакыттан ук кайда, нинди эштә эшли алдым - барсында эшләдем, – дип искә ала ул. - 4 класс белемем бар, сугыш булмаса, бәлки тагын укыган булыр идек әле. Бөтен тормыш безнең кулга калды. Көянтәләп, атларга су ташый идек. Хәтта басуга черемәне дә көянтәләп чыгардык. Иртәнге туң беткәнче өлгерергә кирәк иде. Көч юк, ашарга әз. Аякта тишек чабата. Янсуардан (Кукмара районы) симәнә ташыдык. Пот ярым бодайны су ерып, җилкәдә күтәреп алып кайта идек. Соңрак Саурышка урман кисәргә йөрдек. Үгез җигеп көлтә ташый, агач утыртырга йөри идек. Колхоздагы бер эштән дә калмый идек,” - дип хәтирәләрен яңартты Мәдинә апа.”Сугыш беткән дигән хәбәрне бакчада бәрәңге утыртканда укытучыбыз Разыя апа килеп әйтте. Бөтенебез шатлыктан еладык” ,- ди ул.

1957 нче елда Юлбат авылына Хәбибрахман абыйга тормышка чыга. Дүрт бала үстерәләр: уллары - Данил, Раил, Рамил һәм кызы Гөлнур. Хәбибрахман абый белән 54 ел бергә яшиләр. 2013 елда Хәбибрахман абый вафат була. Бүгенге көндә Мәдинә апа Юлбат авылында улы Раил белән гомер итә.

Тыл ветераны, 1995 елда “1941-45 еллардагы батыр хезмәте өчен” медале, Бөек Җиңүнең 30, 40, 50, 55, 60, 65, 70 еллык юбилей медальләре белән бүләкләнә.

# Хужина (Гыйльметдинова) Рауза Гыйльметдин кызы



Әни 1923 елның 3 сентябрендә Саба районы Урта Саба авылында Хисаметдинов Гыйльметдин һәм Фәхретдинова Гайникамал семьясында ярлы крестьян гаиләсендә туа. 1937 елда Казан педагогия училищесына читтән торып укырга керә. 1938 елда Йосыф - Алан авылына башлангыч мәктәпкә укытучы итеп билгеләнә һәм бу авылда торып укыта башлый.

1946 елның август аенда Йосыф - Алан егете Хуҗин Гәбдрәфыйкка кияүгә чыга. Бер - бер артлы 4 бала дөньяга килә: 3 кыз, 1 малай. Һәрберебез тормышта үз юлын тапты.

Әни укыта башлаганда, Саба авылыннан булган Әхмәт Ногманович Ногманов белән бергә эшлиләр.

Әти ул елларда бик көчле председатель була. Шуңа күрә аны иң артта калган колхозларны алга бастырырга җибәрәләр. Шуңа күрә без гаилә белән гел күчеп йөрергә мәҗбүр булдык. Әни Юлбат, Теneки, Урта Нырты мәктәпләрендә укытты.

1958 елда без кире Урта Ныртыдан Йосыф - Аланга кайтып, әтиләрнең төп йортын төзекләндереп, шунда тора башладык. Әни бу вакытта Хөсәенова Халисә апа белән эшли башлады. 1959 елда энем туды һәм ул бер ел декрет ялында булды. Халисә апа пенсиягә киткәч, Хатипова Шәфига апа белән эшләделәр. Әни бик намуслы, акыллы укытучы иде.

Әни сугыш башлангач, Саба районыннан, берничә кыз белән, язылып сугышка киткәннәр. Әнинең әтисе аны Шәмәрдән вокзалына ат белән озата менгән һәм әйткән: “ И, кызым, сине генә туйдырырга көчебез җитмәс дисеңмени, ач итмәс идек, китмә,” - дип елап озатып калган. Әни Мәскәүдә

комиссия үтә алмаган һәм исән - имин авылга әйләнеп кайткан. Менә шундый батыр кыз булган ул.

1978 елда лаеклы ялга чыкты. 43 ел буе укытучы булып эшләде. Эш дәверендә мәктәпнең завучы да булды.

Хәзерге көндә әнигә 93 яшь, без аны әти өчен салып бирелгән, яңа өйдә 3 кызы кадерләп, тәрбияләп торабыз. Йосыф - Алан авылында гомер итә. Әниебез бик сабыр, һәм түземле, безгә гел рәхмәтләр генә укып тора. Әтиебез дә бик гадел, акыллы тырыш кеше иде.

Тыл ветераны. “Полный ковалер Красной звезды” ордены, 1995 елда “1941-45 еллардагы батыр хезмәте өчен” медале, Бөек Җиңүнең 30, 40, 50, 55, 60, 65, 70 еллык юбилей медальләре белән бүләкләнде.

Без, аларның балалары, әти белән әнигә безне дөньяга тудырган һәм кеше итеп үстергән, тормышта үз юлыбызны табарга өйрәткәннәре өчен, гомер буе рәхмәтлебез.

Кызы Фирдәвес апа сөйләгәннәрдән.

# Бәдегытдинова (Мөбәрәкшина) Зәмфәрия Кәшип кызы

1930 нчы елның 8 августында Саба районының Тенеки авылында крестьян гаиләсендә икенче бала булып дөньяга килә. Гаиләдә алар 4 кыз булалар. Үзе сөйләгән буенча, Тенеки авылында 4 сыйныф белем ала. Моннан соң, тормышлары бик авыр булганлыктан, колхозда эшли башлый.

Берсеннән-берсе кечкенә 4 бала булган бу гаиләдә эти-әниләренә тормышны алып баруы бик авырга туры килә. Кычыткан, черек бәрәңге ашап, иске кием киеп яшиләр алар. Ләкин шулай булса да, тормыш авырлыкларына бирешмиләр, сынмыйлар.

Сугыш башлануын Мөбарәкшиннар гаиләсе күрше-күлән сөйләгәннәрдән беләләр. Озак та үтми, Кәшип абыйны сугышка алалар. 20 көнгә ялга кайтарып торалар да, яңадан алып китәләр. Шул китүеннән ул инде әйләнеп кайтмый. Бары тик үле хәбәре генә килә. Бәләкәй Зәмфәрия ул вакытта әле 8 яшьлек кенә була. Дошманнарның җиңелүен, сугыш бетүен алар солдатлар сугыштан кайта башлагач кына беләләр.

1952 елда Саба районы Юлбат авылында Зәмфәрия апа Бәдегытдинов Дәүлигә кияүгә чыга. Бик матур гаилә коралар: 3 малай, 2 кызлары дөньяга килә. Уллары Фазыл кечкенә чакта ук үлеп китә, кызлары Венера 7 яшендә суга бата, уллары Салават 2007 нче елда вафат була.

2 балалары хәзерге вакытта исән-сау. Кызы Чулпан үзенең гаиләсе белән Апас районында гомер кичерә, улы Айдар Саба районы Юлбат авылында шулай ук үз гаиләсе белән төп йортта яши.

Лаеклы ялга чыкканчы, Зәмфәрия апа Юлбат авылы кибетендә эшли.

Бүгенге көндә Саба районы Юлбат авылында, улы Айдар, килене Рәмзия тәрбиясендә яши. 2015 елның августында 85 яшен тутырды. Нәсел дәвамчылары булып торучы 6 оныгы, 5 оныкчыгы бар. Барысы да аның хәлен белеп, аралашып яшиләр. Сугыш чоры баласы буларак, үзенең хезмәтләре өчен тыл ветераны, 1994 елда “1941-45 еллардагы батыр хезмәте өчен” медале, Бөек Җиңүнең 30, 40, 50, 55, 60, 65, 70 еллык юбилей медальләре белән бүләкләнгән.